

# Тойгелде мәктәбе тарихы



**1883 нче елның 31 октябрендә** Тойгелде авылында беренче мәктәп ачыла.
**1882** нче елда Оренбург татар укытучылары мәктәбен тәмамлаган Абдулханнанов укытырга килә.
**1895** елдан мәктәп урыс-татар училищесы
дип атала башлый. Анда 20 малай белем алган. Ике укытучы исәпләнә: Казан мәдрәсәсен тәмамлаган дин укытучысы  һәм Казан татар укытучылары мәктәбендә белем алган Байтирәков. Уку дүртьеллыкка әверелә.
**1916** елда, ягъни революция алдыннан да училище дип исемләнгән Тойгелде мәктәбендә әллә ни үзгәреш күренми.Ул элеккечә бер класслы.Укучылар-малайлар гына, аларның саны да артмый диярлек. Укытучылары -берәү.




Мәктәп **рус-башкорт балалары өчен дип исемләнгән**. Күрәсен,ул вакытта аны татар балалары өчен ачу мөмкин булмаган.

Революция һәм гражданнар сугышыннан соң **1920** елда Тойгелдедә кабаттан башлангыч мәктәп ачыла, укытучы булып **Гафуров Харис** эшли.

**1927-1928** елларда Мәллә елгасы буендагы таш мәктәпкә 1 сыйныф укучылары кабул ителә. Мәктәп бинасының нигезен Мәллә елгасы суы ашаганлыктан, соңрак мәктәп җимерелә.Әлеге мәктәптә беренчеләрне **Ибраһимова Маһира**, икенче-өченчеләрне **Гафуров Харис** укыткан.

Таш мәктәп җимерелгәч, V сыйныф укучылары мәчет бинасында укыганнар. Укытучылары **Ситдийков Салих** була.

**1929** елда яңа мәктәп салына.



**1930-31** нче уку елларында гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү кертелә.
**1934-35** нче уку елында мәҗбүри җидееллык белем бирү турында закон чыга, шул ук елда беренче җидееллык чыгарылыш була.
**1943** елның июнь аенда кичке мәктәп бинасы эшли башлый. Көндезен бөтен халык хезмәт фронтына чыга, кичләрен белем ала.



1948 елда җидееллык мәктәп коллективы









Җитмешенче еллар

1961-1982 елларда мәктәп сигезьеллык буларак эшли.

1969-1970 елларда яңа мәктәп бинасы төзелә. Сонрак бу бинада коррекцион мәктәп урнашкан.

1982 елда яңа таш бина сафка тапшырыла.

1982-1989 уку елында мәктәп уньеллык итеп үзгәртелә.

1990 -2016 ел арасында  11 еллык уку була.

2016 елдан  9 еллыкка үзгәртелә.

# 1920 елдан **директор** булып эшләүчеләр

| | |
|---|---|
| Гафуров Харис | 1920-1930 |
| Хәсәнов | 1930-1931 |
| Бакыев Сәхаб Бакый улы | 1932-1933 |
| Фәйзетдинов Хәсән Фәйзетдин улы | 1933-1936 |
| Биккузин Рәшит Габдрахман улы | 1937-1941 |
| Нигъмәтуллина Мөнәззәһә | 1941 |
| Баязитов Гали Баязит улы | 1941-1942 |
| Талибулллин Әхтәм Талибулла улы | 1942-1943 |
| Яһудина Галия Һади кызы | 1943-1946 |
| Мәйлүнов Мирзаһит Мәйлүн улы | 1946-1949 |
| Шәйхетдинов Яхъя Шәйхетдин улы | 1949-1983 |
| Вәлиев Мөнәвир Мөхәммәт улы | 1983-1985 |
| Хафизов Факил Мөхтәсим улы | 1985-1986 |
| Низаметдинова Әнисә Әнәс кызы | 1986-1987 |
| Йосыпов Габделәхәт Һади улы | 1987-2010 |
| Смелов Рөстәм Роберт улы | 2010-2014 |
| Мирхайдаров Марат Ренат улы | 2015-2016 |
| Игнатьева Гүзәл Вәзир кызы | 2016-2018 |
| Габидуллин Наил  Гарифулла улы | 2018 февраль-май |
| Фархетдинов Айнур Рөстәм улы | 2018 май |

# Укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары

| | |
|---|---|
| Ахунов Вагыйз Ахун улы | 1933-1935 |
| Галиев Әскәр Мөхәммәтгали улы | 1935-1938 |
| Дубалов Иван  Михайлович | 1935-1938 |
| Валиева Җиһан | 1938-1942 |
| Исмәгыйлова Мәрьям | 1943-1944 |
| Шакирҗанов Хәмит | 1942-1945 |
| Шәйхетдинов Яхъя Шәйхетдин улы | 1946-1949 |
| Гомәрова Мәрнүсә Гомәр кызы | 1949-1980 |
| Нургалиева Илсөяр Таһир кызы | 1980-1983 |
| Хафизов Факил Мөхтәсим улы | 1983-1985 |
| Низаметдинова Әнисә Әнәс кызы | 1987-1994 |
| Хөсәенова Гыйльменур Мөхәмәтҗан кызы | 1994-1996 |
| Заялова Лира Нурфаяз кызы | 1996-2001 |
| Хаҗиева Нурзидә Котдус кызы | 2001-2015 |
| Игнатьева Гүзәл Вәзир кызы | 2016-2017 |
| Шаяхметова Миләүшә Мөдәррис кызы | 2016-2017 |
| Галиева Ләйсән Ирхәт кызы | 2018 |
| Ризатдинова Айгөл Мөдәррис кызы | 2019 |

# Тойгелде мәктәбендә укыткан түбәндәге укытучылар Бөек Ватан сугышында катнашканнар:

1. Ахунов Вагыйз
2. Каримов Мирсает -лейтенант
3. Талибуллин Әхтәм
4. Батырханов Сает- лейтенант
5. Халимов Әслах-капитан
6. Шайхетдинов Яхия-лейтенант
7. Калимуллин Габидин- лейтенант
8. Биккузин Рәшит-өлкән лейтенант
9. Биккузин Рәүф-лейтенант
10. Гыйләҗев Хисам
11. Шәрифуллин Сәет
12. Ганиев Яхия-лейтенант
13. Ганиев Шәехвәли
14. Дубалов Иван
15. Ахметшин Иван
16. Баязитов Гали



# Укытучыларыбызның тормыш юллары ...





Шайхетдинов Яхъя Шайхетдин улы1919 нчы елның 29 маенда Мөслим районы Тойгелде авылында туган. Мәктәпне тәмамлагач Минзәлә педагогия училищесында белем ала. Яхъя Шайхетдин улы 1940 нчы елның июнь аеннан 1941нче елның  май аена кадәр 39 нчы запастагы укчы полкта хезмәт итә.1941 нче елның май аеннан декабрь аена кадәр Сухуми шәһәрендә хәрби училищеда укый. 1941 нче елның декабреннән 1942 елның май аена кадәр 328 нче укчы дивизиядә взвод командиры була. Керчь шәһәрен алуда катнаша. 1942 нче елның 15 маенда каты яралану сәбәпле госпитальдә ята.

1943 нче елның декабрь аеннан Тойгелде җидееллык мәктәбендә военрук булып эшли.1945-1949 нчы елларда физкультура укыта. Ә 1949-1983 елларда мәктәп директоры һәм укытучы булып эшли. Бер үк вакытта 1949 нчы елдан 1957 нче елга кадәр “Кызыл сабанчы” колхозында партия оешмасы секретаре булып эшли. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бик күп

7oom.ru

# Кәлимуллин Габидин Шәйхетдин улы



Кәлимуллин Габидин Шәйхетдин улы **1914** нче елда Мөслим районы Тойгелде авылында туа. **1939** нчы елда хәрби хезмәтне тутырып авылга кайта. Шул ук елны авыл мәктәбендә **башлангыч классларны укыта** башлый. Югары классларда **физкультура укытучысы** була. Габидин ага Минзәлә педучилищасын тәмамлый.
Финляндия сугышы башлана, ул тагын хәрби хезмәткә алына. Сугыш вакытында Мәләкәстә офицерлар хәзерли торган Хәрби училищасында укып, кече лейтенант дәрәҗәсен алып чыга. Бөек Ватан сугышы башлангач, **1941** елның 24 июнендә **сугышка китә**. **1942** елның маена кадәр Казанда Хәрби заводны саклый. Шул ук айда икенче Украина фронты составында сугышка керә. Чехословакияне, Венгрияне, Польшаны, Болгарияне, Румынияне азат итүдә катнаша. Җиңү көнен Берлинда каршылый.
**1944** елда партия сафына керә. Сугыш беткәннән соң, **1945** елда авылга кайта. Габидин Шәйхетдин улы сугыштан соңгы бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә, укытуга багышлый. **Тойгелде сигезьеллык мәктәбендә 40 ел укыта**. Ул балаларда Туган илне ярату, хезмәт сөю, чын кеше булу сыйфатларын тәрбияли.
Ул **1986** елның 23 нче февраленда вафат булган.

7oom.ru

## Гыймаева Рәисә Насретдин кызы

1923 нче елның 11 нче декабрендә Тойгелде авылында туган. Минзәлә башлангыч класс укытучылары хәзерли торган училищега кабул ителә. 1939 нчы елның көзендә Фин сугышы башлану сәбәпле, уку түләүлегә әйләнә һәм байтак укучы укуын ташлый. Ләкин ул дәвам итә.

Рәйсә апа түбәндәгеләрне сөйли:

“1941 нче елның 21 нче июнендә Германия сугыш башлады. Безне шул елны 3 нче чакырып алты ай эчендә укытып, сынау бирдереп **укытырга** җибәрделәр.

1942 нче елның 12 нче январеннән Тегермәнлек башлангыч мәктәбендә **1-3 нче классларны укыта** башладым . Минем күпчелек укыту елларым Тойгелде мәктәбенә туры килде. **40 ел стажымның** 30 елга якыны авылда эшләргә насыйп булды, чөнки миңа әти-әнине тәрбияләргә кирәк иде.

Укытуымнан зарланмыйм, мин үзем балаларны яраттым, алар мине яратты. РОНОдан килгән методистлар дәрес бирүемне яратып, мактап китә иделәр. “

Рәйсә апа “Бөек Ватан сугышы ветераны”, “Хезмәт ветераны” медальләре белән бүләкләнгән. Хәзер лаеклы ялда, Чаллы шәһәрендә балалары янында яши.



Ганиев Шәйхевәли Әхмәтвәли улы.

Шәйхевәли ага Ганиев - тирән ихтирам казанган аксакал. Хәрчак кешеләр арасында була. Шәйхевәли агайга беренче булып кул бирәләр. Чөнки ярты авыл аның укучылары, ярты авыл Шәйхевәли аганы яшь чагыннан бирле бары тик яхшы яктан гына белә.

Аерылмас җан дуслары Мохтәр Идиятуллин, Галимҗан Хафизов белән бергә су коенып, уйнап усәләр. Үсмер чакта ук өлкәннәр белән тигез йөк тартырга туры килә узләренә. Җир сөрү, тырмалау, кибән ташу, көлтә суктыру кебек эшләрнең берсеннән дә читтә калмый. Шундый михнәтле коннәрнең берсендә мәктәпкә хәрби комиссариаттан повестка килеп төшә.

1943 нче елның 9 нчы гыйнварында әле 17 яшьләре тулмаган егетләр, ата - аналар хәм укытучылар белән саубуллашып, хәрби хезмәткә китәләр. Яшьтәшләрен Ерак Көнчыгышка озаталар.

Сугыштан соң туган авылына кайтып эшкә урнаша.

Шәйхевәли ага Мәрнүсә Гомәрова белән ныклы гаилә корып өч бала үстерә. Барсына да югары белем бирәләр. Уллары Илфак Казанда яши, кызлары Рәмилә - КамАЗнын махсус техник китапханәсе мөдире, Дилбәр исә ата-анасы хөнәрен сайлады. Ленинградта аспирантура бетереп, Казан мәдәният институтында декан булып эшли. Дүрт оныгының - күз нуры, күңел юанычлары аның. "Сөекле бабабыз," -дип кенә торалар.

Шәйхевәли аганың сабырлыгы олы йөрәклелеге хәркемне сокландыра. Гаиләдә хәркемгә урын түрдән булды. Сукырайган атасын бер кыенлык күрсәтмичә 15 ел тәрбияледеләр, әнисенә ихтирам күрсәттеләр. Хатыны Мәрнүсәне каты авыру аяктан еккач, бер көн янынннан китмичә янәшә булды. Аны 16 ел карады. Бу вакыт эчендә Шәйхевәли ага авызыннан бер уфтану сүзен ишетүче, борчулы йөзен күрүче булмагандыр. Хәр туган көнгә куанып яшәде, куңелендәге борчу - кайгыларын түкмәде - чәчмәде.

## Галиева Гөлфирә Нурулла кызы

1944 нче елның 1 нче гыйнварендa Мөслим районы Катмыш авылында эшче гаиләсендә дөньяга килгән.

1962 нче елда Мөслим ура мәктәбен уңышлы тәмамлап, Алабуга Дәүләт педагогия институтына укырга кергән. Аны 1966 нчы елны тәмамлап,Мөслим мәгариф бүлеге юлламасы белән Ташлыяр сигезьеллык мәктәбенең **4 нче классын укыта** башлаган.

Ташлыяр сигезьеллык мәктәбендә ике ел **башлангыч класслар укыткан** һәм шул к вакытта мәктәпнең **укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары** булып эшләгән.

Ташлыярда эш чорында 5 ел “Ватан” исемендәге комсомол политукуында яшьләрне укыткан.Намуслы хезмәте өчен ВЛКСМ Үзәк Комитеты 1968 нче елда Мактау грамотасы белән бүләкли.

1973 нче елның 1 нче сентябреннән Тойгелде сигезьеллык мәктәбенең **башлангыч классларында укыта** башлаган.

Гөлфирә Нурулловнаның **гомуми эш стажы 35 ел**.

Гөлфирә Нурулловна күпьеллык эш тәҗрибәсендә балаларның сөйләм телен үстерү өстендә даими эшләгән. Ул **2000** нче елдан лаеклы ялда.

## Галиева Гөлфирә Нурулла кызы

1944 нче елның 1 нче гыйнваренда Мөслим районы Катмыш авылында эшче гаиләсендә дөньяга килгән.

1962 нче елда Мөслим ура мәктәбен уңышлы тәмамлап,Алабуга Дәүләт педагогия институтына укырга кергән. Аны 1966 нчы елны тәмамлап,Мөслим мәгариф бүлеге юлламасы белән Ташлыяр сигезьеллык мәктәбенең **4 нче классын укыта** башлаган.

Ташлыяр сигезьеллык мәктәбендә ике ел **башлангыч класслар укыткан** һәм шул к вакытта мәктәпнең **укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары** булып эшләгән.

Ташлыярда эш чорында 5 ел "Ватан" исемендәге комсомол политукуында яшьләрне укыткан.Намуслы хезмәте өчен ВЛКСМ Үзәк Комитеты 1968 нче елда Мактау грамотасы белән бүләкли.

1973 нче елның 1 нче сентябреннән Тойгелде сигезьеллык мәктәбенең **башлангыч классларында укыта** башлаган.

Гөлфирә Нурулловнаның **гомуми эш стажы 35 ел**.

Гөлфирә Нурулловна күпьеллык эш тәҗрибәсендә  балаларның сөйләм телен үстерү өстендә даими эшләгән. Ул **2000** нче елдан  лаеклы ялда.

# Нуриева Әлфия Исмәгыйловна

1941 нче елның 1 нче июнендә Вәрәшбаш авылында туа. Башлангыч белемне Вәрәшбаш сигезъеллык мәктәбендә, урта белемне Мөслим урта мәктәбендә ала. Хезмәт юлын Усы сигезъеллык мәктәбендә башлый. Читтән торып Алабуга пединститутын тәмамлый. 1967 нче елдан Тойгелде урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта. Класс җитәкчесе булып эшли, 4 чыгарылыш класс чыгара.Әлфия апа мәктәптә эшләгән дәвердә узен теоретик яктан хәзерлекле укытучы итеп таныта. Аның дәресләрендә укучылар сәнгатьле укырга ,әдәбиятны яратырга , төгәллеккә һәм актив эшчәнлеккә өйрәнәләр. Үз фәненә укучыларда кызыксыну уята һәм тулы өлгерешкә ирешә ала. Укучылар да чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшыралар. Үз фәне буенча район олимпиадаларында һәм республика күләмендә призлы урыннар алуга ирешә.Әлфия апа үзенең эш тәҗрибәсе белән теләп уртаклаша . Ачык дәресләрендә, яңа материалны аңлатканда, тормыш белән бәйләп алып бара. Укучыларның кызыксынучанлыгын үстерә, яшь укытучыларның остазы булып тора. Әлфия апа җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Хезмәтен хөрмәтләп район мәгариф бүлеге һәм мәгариф министрлыгы бүләкләр бирә.

1. 1978г . По предложению аттестационной комиссии объявлена благодарность.

2.1983 г. по предложению республиканской аттестационной комиссии награждена Почётной грамотой М.П.ТАССР и ОК профсоюза.

3. С 1989 года - "Старший учитель".

4. С 1992 года -"Учитель методист".

5. С 2002 года -Почетный работник общего образования РФ.

# Ильясова Асия Габидин кызы



**1948** нче елның 25 нче июлендә Мөслим районы Тойгелде авылында туган. **1971** нче елның 1 нче с ентябреннән Тойгелде сигезьеллык мәктәбенең озынайтылган көн группасында тәрбияче булып эшли башлаган. **1994** нче елның 14 нче январендә "**Өлкән тәрбияче**" дигән квалификацион категория бирелә.
1994 нче елның 19 нчы январендә шул ук мәктәптә **пионервожатый** булып эшли башлый, **хезмәт дәресләре укыта**. 1972-1973 нче уку елларында 2-3 нче классларны укыта.
1976 нчы елның 15 нче маенда Казан педагогика училищесын тәмамлый.
2001 нче елдан "**Педагог-оештыручы"** квалификациясен ала.
Асия Габидин кызы 2005 нче елның 25 нче августыннан лаеклы ялга чыга.

**Бүләкләре:**

7.12.1998 елда- "Хезмәт ветраны" таныклыгы;
Медаль- "За доблестный труд в ознаменование 100-летия со дня рождения В.И.Ленина";
1.09.1989 ел- "Урып-җыю чорында актив катнашуы өчен" мәктәп дирекциясе, партком, авыл советы һәм профком грамотасы;
1996 ел- Мөслим РОНОсы и профсоюзлар райкомы грамотасы "В связи с 25-летием педагогической деятельности".

# Идиятуллина (Николаева ) Валерия Фома кызы.

Идиятуллина (Николаева )Валерия Фома кызы 1926 нчы елда Мөслим районы Яңа усы авылында туган.

Мөслим урта мәктәбен 1943 нче елда тәмамлаган. Районда укытучылар җитмәү сәбәпле, район мәгариф бүлеге аңа укытучы булырга тәкъдим иткән. Минзәлә педагогия училищесында педагогика,психология фәннәрен үзләштергән,фәннәрне укыту методикасын өйрәнгән. Курсларны тәмамлагач, аны **Олы Чакмак** авылына эшкә җибәргәннәр. **Укытучылык эшен ул шунда башлаган**. Аннары Ольгино җидееллык мәктәбендә детдом балаларын укыткан.

1948 нче елның гыйнвар аенда Тойгелде җидееллыек мәктәбенә **рус теле укытучысы** итеп җибәргәннәр.Берничә ел эшләгәннән соң, **башлангыч класслар** укыта башлаган. Шул ук вакытта читтән торып укыган.1956 нчы елда Бөгелмә укытучылар институтын тәмамлаган. “Тойгелде мәктәбе коллективы мине ачык йөз белән каршы алды.Укытучылардан күп нәрсәгә өйрәндем “,-дип искә ала торган булган Валя апа.Ул җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, агитатор, пропагандист булып эшләгән. Укучылар белән бәрәңге,чөгендер алуда совхозга ярдәм иткән.

1976 нчы елда Валя Фома кызы Тойгелде интернат мәктәбеннән лаеклы ялга чыккан.

# Гүзәл Мортаза кызы

**1946-47** нче уку елында Тойгелде авылына татар теле укытырга килә. Ул Бондюг (хәзерге Менделеевск районы) Псәй авылы кызы.

Гүзәл апа үзенең үткәннәре турында сөйләгәндә : “Мөслим районына без өч кыз килдек.Тойгелде авылы Мәллә елгасы кырында дигәч,кызыгып килдем. Мәктәптә балалар бик күп иде. Кичке мәктәптә зурлар укый иде.Габидин абый белән экзамен алабыз. Асмабикәтти такта янына чыкты да тактага түгәрәк ясап куйды,тагы ясады да һәм:”Менә мин ничек укырга,язарга өйрәндем”,-диде. Без көлдек. Элек укытучыларны бик хөрмәт итәләр иде. Балалар ач-ялангач иделәр.

Мәктәп бакчасында яшелчә үстердек. Балалар күбрәк кишер ашыйлар иде.Күз күне балаларның тамагы туя иде. Яшелчәне мәктәптә тәрәзә төбендә дә үстердек. Мәктәптә укучылар үзләре балчык чүлмәкләр ясый иделәр. Шуларга тирес белән көл кушып үсенте утырта идек.Төрле эшләрдә катнаштык: мәктәпкә утын кисәргә бардык,кул урагы белән урак урдык. Шулай ук катлаулы молотилкада эшләдек. Мәктәптә план төзеп,дәфтәр тикшереп кич белән генә кайта идек. Клубка да йөрдек. Безне-укытучыларны хөрмәт итә иде авыл халкы. Урамнан узганда исәнләшеп юл биреп китәләр иде.Коймалар читәннән,ихаталар тәртипсез рәвештә урнашкан. Көзге пычрак вакытта балалар күтәртмәле чабата белән килә иделәр. Мәктәптә тузан була иде.”

# Вәлиев Мөнәвир Мөхәммәт улы



**1953** нче елның 17 нче сентябрендә Мөслим районы Тойгелде авылында туа. **1960** нчы елда Тойгелде сигезьеллык мәктәбенә укырга керә һәм аны уңышлы гына тәмамлый.
Техникумны тәмамлаганда Вәлиев Мөнәвир чаңгы спорты, йөгерү, гимнастика буенча I разрядлы, ирекле көрәш буенча “Спорт мастеры кандидаты” исемнәрен ала. Барыннан да бигрәк ул татарча көрәш спортын ярата һәм шул төр буенча республика күләмендә танылa.

Техникумны тәмамлагач, Мөслим районы Тат.Буләр урта белем бирү мәктәбенә **физик культура укытучысы** итеп җибәрелә, купләгән укучыларда спортка карата мәхәббәт уята. Ул шул вакытта, Казанның физик культура институтына читтән торып укырга керә һәм югары белемле спорт белгече исеменә ия була. Ул спортның күп төрләре буенча **1 нче категорияле судья** була.

Вәлиев Мөнәвир узенең эшен Түбән Табын һәм Тойгелде авылларының урта белем бирү мәктәпләрендә дәвам итә. Үз һөнәре буенча Мөслим районында бик күп спортчылар әзерли. Тойгелде урта белем бирү мәктәбендә мәктәп директоры вазыйфаларын башкара.

# Ситдикова Суфия Рәфкать кызы

**1962** нче елның 6 нчы гыйнваренда Мөслим районының Тойгелде авылында туган.
**1969** нчы елда Тойгелде урта мәктәбенә укырга кергән.Беренче укытучысы-Николаева Валерия.
Мәктәптә укыганда рәсем.география,рус теле фәннәрен яратып укыган.
**1977** нче елны Тойгелде сигезьеллык мәктәбен тәмамлап,Лениногорск педагогия училищесына укырга кергән. Аны **1981** нче елны тәмамлап,Ташлыяр мәктәбенә **башлангыч классларны** укытырга кайткан.
**1982** нче елда Тойгелде мәктәбенә **башлангыч класслар** укытырга күчкән.
Озак еллар дәвамында башлангыч классларга белем һәм тәрбия биргән. Суфия Рәфкать кызы хәзерге көндә лаеклы ялда.

## Шәйхетдинова Дәрия Амур кызы



**1964** елның 2нче октябрендә Сарман районы Яхшыбай авылында туа. **1982** елда Иске Кәшер урта мәктәбен тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә. **1987** елда Алабуга дәүләт институтының физмат факультетының математика -физика бүлеген бетергәннән соң, Ташлыяр мәктәбендә **математика укыта.** Соңрак **2010** елда Ташлыяр мәктәбе башлангычка калу сәбәпле, Тойгелде мәктәбенә эшкә килә.

**2019** елда лаеклы ялга чыга.



## Габдуллина (Рөстәмова) Сәкинә Җәүдәт кызы

*1962 елда Мөслим районы Мәлләтамак авылында туа. 1979 елда Мәлләтамак урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә. 1984 елдан Тойгелде урта мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә. 33 ел укучыларга* ***физика һәм информатика*** *фәннәренең нигезләрен өйрәтә. 2017 елдан лаеклы ялда.*

**Энҗе Фарис кызы Габидуллина**

Чыгышы белән ул Мөслим районы Баланны авылыннан. Ул гаиләдә икенче бала. **1965** нче елның 10 нчы гыйнваренда дөньяга килгән.

Михайловка мәктәбен 1982 нче елда тәмамлагач, Алабуга Дәүләт педагогия институтына укырга кергән.

1986 нчы елны Мөслим мәгариф бүлеге юлламасы белән Тойгелде урта мәктәбенә **тарих укытучысы** итеп билгеләнгән. 1987 нче елны **башлангыч классларны** укытуга күчкән. Хәзерге көндә Энҗе Фарис кызы лаеклы ялда.



## Низаметдинова Аниса Анасовна

родилась 27 мая 1959 года в д.Тойгильдино Муслюмовского района ТАССР. После окончания Михайловской средней школы в 1976 году поступила в Елабужский государственный педагогический институт на филологический факультет русского отделения. После окончания института в 1982 году начала работать **учителем начальных классов** в Тойгильдинской восьмилетней школе . Затем ,в том же 1982 году, стала преподавать **русский язык и литературу** в Тойгильдинской средней общеобразовательной школе.
В 1986 году ее назначили **директором** данной школы. А с 1987 года по 2000 год Аниса Анасовна проработала **заместителем директора по учебной части**.
В настоящее время она продолжает работать **учителем русского языка и литературы первой квалификационной категории.** Имеет сороколетний педагогический стаж. Награждена Почетной Грамотой Российской Федерации.

# Кунафина Гыйльменур Мехәмәтҗан кызы



1965 елның 12 ноябрендә Мослим районы  Игенче авылында туган. Тойгелде сигезъеллык мәктәбен тәмамлагач, урта белемне Мәлләтамак урта мәктәбендә ала. Мәктәпне 1974 елда  тәмамлый. Ике ел мәктәптә химия, биология фәннәрен укытканнан соң Казан Дәүләт педагогия институтына укырга керә. 1976-1981нче елларда  үзе сайлаган химия, биология фәннәрен үзләштерә.

1987 елга кадәр Тукай районы мәктәпләрендә эшли. Эшен бик яратып башкарганга күрә Калмыя урта мәктәбенең **директоры** итеп билгеләнә. 1987 елда гаилә хәле буенча туган авылы Тойгелдегә кайтып урнаша һәм 2012 нче елның 18 нче августына кадәр шушы мәктәптә белем һәм тәрбия бирә.

**Химия-биология фәннәре** балаларга үзләштерү өчен авыр булса да, укучыларының уңышлары күп була аның. Олимпиадаларда призлы урын яуламый калган еллары гел булмый . Фәнни- тикшерү эшләре белән дә шөгыллләнәләр. Фәне буенча имтиханнар тапшырып югары уку йортларына керучеләр дә күп була.



# Габдулхакова Альмира Габдулхаковна

Габдулхакова Альмира 1959 елның 11 февралендә Арча районының Яна Кенәр авылында туган. 1976 елда туган авылында урта мәктәпне тәмамлый. Ике ел почта бүлегендә эшли.1980 -1985 елларда Казанда авыл хуҗалыгы институтында укый. Агроном дипломы алгач  юлланма буенча Мөслим районына эшкә килә. 2006 елдан башлап лаеклы ялга чыкканчы Тойгелде урта белем бирү мәктәбендә **педагог оештыручы** булып эшли.

## Смелов Рөстәм Роберт улы



1986 нчы елның 23 сентябрендә Мөслим районы Мөслим авылында туа. 2004 нче елда Мөслим урта белем бирү мәктәбен тәмамлый һәм Яр Чаллы дәүләт педагогика институтының география факультетына укырга керә. Институтны тәмамлагач, Мөслим районы Тойгелде урта гомуми белем бирү мәктәбендә хезмәт юлын башлый.

2010 -2014 елларда **мэктэп директоры** вазыйфаларын башкара. 2015- 2016 нчы елларда Метрәй гомуми белем бирү мәктәбендә **тәрбия эшләре буенча директор урынбасары** булып эшли. Бугенгесе көндә Мөслим лицеенда **география укыта.**

Эшләү дәверендә үсеп килүче буынга белем һәм тәрбия бирүдә зур өлеш керткәне өчен Мөслим мәгариф идарәсе һәм Мөслим муниципаль районы Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Районның ижтимагый тормышында актив катнаша.



# Игнатьева Гүзәл Вәзир кызы

1985 нче елның 26 нчы апрелендә Татарстанның Мөслим районы Михайловка авылында гади эшчеләр гаиләсендә туа. Хезмәт юлын 2015 нче елда Мөслим районы Тойгелде урта гомуми белем бирү мәктәбендә **укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары** һәм **технология укытучысы** буларак башлап җибәрә. 2016 нчы елның март аенда шул ук мәктәпнең **директоры** булып билгеләнә.

2018 нче елның февраль аенда үз теләге белән бу вазыйфадан азат ителә һәм Михайловка урта гомуми белем бирү мәктәбенә **тәрбия буенча директор урынбасары, рус теле һәм әдәбияты укытучысы** булып урнаша.

**Миннеханова Айсылу Рәис кызы**

1983 нче елның 7 февралендә Мөслим районы Тойгелде авылында дөньяга килгән.

1989 нчы елда беренче класска укырга килгән. Беренче укытучысы -Вәлиахмәтова Рәмилә. Өлкән классларда класс җитәкчесе- Нуриева Әлфия. Тойгелде урта мәктәбен 2000 нче елда тәмамлап,Түбән Кама педагогия училищесына укырга кергән. 2002 нче елда училищены тәмамлап, Тойгелде мәктәбенә **башлангыч класслар** укытырга килгән.

Тойгелде мәктәбендә 1 ел эшләгән.

## Фәрхетдинов Айнур Ростәм улы.



1981 елнын 15 декаберендэ Мөслим районы Мөслим авылында туа. Мөслим урта мәктәбендэ белем ала.1999 елда Бөгелмэ дәуләт профессиональ - педагогик колледжена укырга керә. 2002 – 2003 елларда Мөслим училищесында мастер булып эшли.2004 елда Чаллы дәуләт педагогия институтына, география булегенә читтән торып укырга керә.2009 елда институтны унышлы гына тәмамлый.2003 - 2006 Мөслим гимназиясендэ **география, технология укытучы** булып эшли.2004 елда бассейн буенча директор урын басары итеп билгеләнә.2006- 2013 елларда Мослим лицеенда география ,технология фәннэрен укыта.2013 елда Айнур Рөстэм улы Олы Чакмак төп гомуми белем биру мәктәбенә **директор** итеп билгеләнә. 2018 елда Айнур Рөстәм улын Тойгелде топ гомуми белем биру мәктәбенә кучерәләр.Бугенге көндә узенен хезмәт корьерасын шушуы мәктәптә директор вазыйфасында давам итә.Татарстан,Россия куләм конкурсларда катнашып яхшы нәтижәләргә ирешә. Бер рәттән авыл жирлегендә оештырылган чараларда катнаша. Жирлек депутаты буларак, халык арасында,аз керемле гайләләрдә туган проблемаларны чишәргә булыша.